РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР
СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 13 ноябре № 46

Түбән Кама шәһәр Советының 2023 елның 20 октябрендәге 41 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 04 августындагы 438-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2023 елның 20 октябрендәге 41 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

13 статьяда 2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләне карау өчен нигезләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясының 2 өлешендә билгеләнгән.».

2. Әлеге карар 2024 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Түбән Кама шәһәре Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр төзелеше сәясәте идарәсенә расланган документны Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Түбән Кама шәһәре Мэры вазыйфаларын
башкаручы, Мэр урынбасары М.В. Камелина